ГЛАВА
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ **КАРАР**

20.08.2018 г. Агрыз № 67

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советында гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү һәм гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау тәртибен раслау турында

“Россия Федерациясендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында”гы Федераль законга 02.05.2006 №59-ФЗ һәм “Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында”гы Татарстан Республикасы Законына 12.05.2003 № 16-ЗРТ тәңгәлләштереп к а р а р б и р ә м:

1. Расларга:

- Әгерҗе муниципаль районы Советында гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибе;

- Әгерҗе муниципаль районы Советында гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ ясау тәртибе.

2. Бу карарны Әгерҗе муниципаль районы сайтына һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталына урнаштырырга.

3. Әгерҗе муниципаль районы Башлыгының “Әгерҗе муниципаль районы Советына кергән гражданнарның язмача һәм телдән мөрәҗәгатьләрен карау һәм анализлау тәртибе турында”гы карары 22.09.2016 №103 көчен югалткан дип санарга.

4. Бу карарның үтәлешенә контрольлек итүне Әгерҗе муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе Р.Ә. Закировага йөкләргә.

Общий отдел
Гомуми бүлек

В.В. МАКАРОВ

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципальрайоны
Башлыгы Карары белән расланган
20.08. 2018 № 67

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советында гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү Тәртибе

1. Гомуми положениеләр

1. Әгерҗе муниципаль районы Советында гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибе гражданнарны кабул итү вакытында, район Советына, район башлыгына язма формада, электрон хәбәрләр яки телдән шәхси мөрәҗәгатьләр формасында шәхси һәм коллектив тәкъдимнәр, мөрәҗәгатьләр, гаризалар һәм шикаятьләрне карауны оештыру тәртибен билгели.

2. Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе, гражданнарга сораулары буенча мәгълүмат бирү, шул исәптән белешмә характерындагы мәгълүмат бирү тәртибе Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнелә.

2. Гражданнарның мөрәҗәгать итү хокукы

1. Гражданнар Советка шәхсән яки үзенең вәкиле аша мөрәҗәгать итәргә, шәхси һәм коллектив мөрәҗәгатьләр җибәрергә хокуклы.

2. Гражданнар мөрәҗәгать итү хокукын ирекле һәм ихтыярый гамәлгә ашыралар. Гражданнар тарафыннан мөрәҗәгать итү хокукын гамәлгә ашыру башка затларньң хокукларын һәм ирекләрен бозмаска тиеш.

3. Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау түләүсез башкарыла.

3. Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау

1. Гражданнарның Советка кергән барлык мөрәҗәгатьләре электрон документ әйләнешенә кертелә һәм теркәлә.

2. Граждан үзенең язма мөрәҗәгатендә язма мөрәҗәгать җибәрелә торган органның исемен, яисә тиешле вазыйфаи затның фамилиясен, исемен, атасының исемен мәҗбүри күрсәтә, шулай ук тәкъдименең, гаризасының асылын бәян итә, исем-фамилиясен, атасының исемен, җавап җибәрелергә тиешле почта адресын йә электрон адресын, имзасын, язылу вакытын куя.

3. Гражданнар тәкъдимнәр, гаризалар һәм шикаятьләр белән Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә, туган телләрендә йә үзләре белгән Россия Федерациясе халыклары телләрендә мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Гражданнарга җаваплар алар мөрәҗәгать иткән телдә бирелә. Андый мөмкинлек булмаганда Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә бирелә.

4. Әгәр язмача мөрәҗәгатьтә гражданинның фамилиясе, адресы күрсәтелмәгән икән, мөрәҗәгатькә җавап бирелми. Әгәр мөрәҗәгатьтә законга каршы эшләр һәм аны әзерләүче зат турында белешмә бар икән, хат тиешле

компетенциядәге дәүләт органына җибәрелә.

5. Әгәр язма мөрәҗәгать укырлык булмаса, аңа җавап бирелми һәм ул карау өчен органнарга һәм вазифаи затларга җибәрелми һәм фамилиясе, адресы укырлык булса, җиде көн эчендә аңа бу турыда хәбәр ителә.

5.1. Әгәр язма мөрәҗәгатьнең асылы аңлашылмаса, аңа җавап бирелми һәм органнарга йә вазифаи затка карау өчен җибәрелми һәм бу турыда гражданга җиде көн эчендә хәбәр ителә.

6. Органга йә вазифаи затка электрон формада кергән мөрәҗәгать закон кысаларында карала. Граждан хатында исем-фамилиясен, атасының исемен, электрон почта һәм почта адресын күрсәтергә тиеш. Граждан мондый мөрәҗәгатькә электрон формада кирәкле документларны куярга хокуклы. Йә аларның күчермәләрен язма формада җибәрә ала.

6.1. Органга йә вазифаи затка кергән мөрәҗәгать билгесез төремдәге затларның мәнфәгатьләрен чагылдырса, аерым алганда суд карарын кире кагып язган мөрәҗәгатькә җавап Әгерҗе муниципаль районы рәсми сайтына урнаштырылырга мөмкин. Бу турыда гражданинга җиде көн эчендә рәсми сайтның адресын язып хәбәр ителә. Суд карарын кире кагып язылган мөрәҗәгать кире кайтарылмый.

7. Гражданның мөрәҗәгате җибәрелгән вазифаи затның вәкаләтләре туктатылса, хат әлеге вәкаләтләр йөкләнгән зат тарафыннан карала.

8. Советка кергән язмача мөрәҗәгатьләр өч көн эчендә теркәлү уза һәм адресланган вазифаи затка җибәрелә.

9. Әгәр граждан мөрәҗәгатендә күтәрелгән мәсьәләләр Совет компетенциясенә кермәсә, хат җиде көн эчендә тиешле органга йә тиешле вазифаи затка җибәрелә. Советның гомуми бүлеге баш белгече хатны кая җибәрелүен хәбәр итеп имзасын куеп уведомление җибәрә.

10. Язма мөрәҗәгатьтәге сораулар берничә орган йә берничә вазифаи затка кагыла икән, хатның күчермәсе теркәгәннән соң җиде көн эчендә барысына да җибәрелә.

11. Вазифаи зат мөрәҗәгатьне карау өчен җаваплы затны (алда - башкаручы) билгели һәм Электрон Хөкүмәт аша җавап әзерләү өчен мөрәҗәгатьне җибәрә.

12. Башкаручы тиеш:

- гаризаны карарга;

- граждан гаризасы буенча элек кабул ителгән карарларның үтәлешен исәпкә алырга;

- нигезләнгән карар кабул итәргә һәм аның үтәлешен тәэмин итәргә;

- гариза биргән гражданга гаризасын карау нәтиҗәләрен әйтеп һәм кабул ителгән карарны хәбәр итәргә;

- гаризада язылган таләпләр үтәлмәгән очракта гражданга кире кагылу сәбәпләрен, шулай ук әлеге карар белән риза булмаган очракта мөрәҗәгать итәргә мөмкин булган орган һәм вазифаи затны күрсәтеп хат җибәрергә.

13. Советның гомуми бүлеге баш белгече җавапның проектын Башлыкка, Башлык урынбасарына йә аппарат җитәкчесенә җибәрә.

14. Баш белгеч җавапны терки һәм гариза бирүчегә җибәрә. Җавап

электрон почта аша электрон документ формасында йә почта адресына язмача җибәрелә.

15. Карарга гражданнар шикаяте карау өчен Советның әлеге вазифаи затларына җибәрелми.

16. Бу очракта шикаять гражданга кире кайтарыла һәм әлеге карар буенча билгеләнгән тәртиптә судка мөрәҗәгать итәргә хокукы булуы аңлатыла.

17. Гражданнар мөрәҗәгатьләре теркәлгәннән соң Советта 30 көн эчендә карала.

18. Хатны карау вакыты озайтылган очракта Советның гомуми бүлеге баш белгече мөрәҗәгатьне карау вакыты озайтылу расланганнан соң гариза язучыга бу турыда хәбәр бирә. 30 көннән дә артык булмаган вакытны, сәбәбен һәм озайту вакытын күрсәтеп хәбәр итә.

19. Мөрәҗәгать итүченең хаты аноним булганда башкаручы аны җавапсыз калдыру турында заключение әзерли һәм мөрәҗәгатьне Советның гомуми бүлеге баш белгеченә тапшыра, гражданнар хатлары белән эшләүгә җаваплы зат аны Электрон Хөкүмәттә терки һәм аның буенча эшләү туктатыла. Әгәр мөрәҗәгатьтә хокукка каршы әзерләнүче, башкарылучы йә башкарылган гамәл турында , шулай ук агы әзерләүче, башкарган йә башкаручы зат турында белешмәләр булса, мөрәҗәгать итешле компетенциядәге дәүләт органына җибәрелергә тиеш.

20. Орган йә вазифаи зат Советның үтенечнамәсе буенча 15 көн эчендә мөрәҗәгатьне карау өчен кирәкле документларны һәм материалларны тапшырырга тиеш. Моңа дәүләт серен йә федераль закон белән сакланучы башка серне тәшкил итә торган һәм алар өчен бирүнең аерым тәртибе билгеләнгән белешмәләре булган документлар һәм материаллар керми.

21. Таләп ителгән дәлилләрне бирмәүдә гаепле вазифаи зат закон ингезендә җавап тота.

22. Гаризасы, шикаяте, тәкъдиме буенча кабул ителгән карар белән риза булмаучы әлеге карарны кабул иткән органны бу орган турыдан-туры буйсынган органга йә вазифаи затка йә судка бирергә хокуклы.

4. Гражданнарны шәхси кабул итү

1. Гражданнарны шәхси кабул итү Башлык тарафыннан һәр сишәмбе 14-16 сәгатьләрдә үткәрелә, вәкаләтле вазифаи затлар – һәр дүшәмбе 13-15 сәгатьләрдә якынча язылу буенча. Гражданнарны кабул итү урыны, көне, сәгате, кабул итүгә әзерлек өчен җаваплы вазифаи затның телефоны районның рәсми сайтына, Совет бинасындагы (Әгерҗе, Гагарин урамы, 13) стендларга урнаштырыла.

2. Атна дәвамында Башлыкка шәхси кабул итүгә алдан язылу алып барыла. Гражданнарны кабул итү исәбе теркәү карточкасын тутыру ярдәмендә башкарыла һәм теркәлеп, электрон документ әйләнешенә кертелә. Кабул итү вакыты гражданга өстәмә рәвештә телефоннан хәбәр ителә.

3. Шәхси кабул итү вакытында граждан мәсьәләләрнең асылын аңлата, аңа телдән аңлатма бирелә. Шәхси кабул итү карточкасына гражданның

соравы, аның буенча карар (1нче кушымта) кертелә. Гражданның ризалыгы белән мөрәҗәгатькә җавап кабул итү барышында бирелә һәм шәхси кабул итү карточкасына языла. Әгәр граждан телдән җавапка риза булмаса, язмача җавап бирелә.

4. Беренче чиратта шәхси кабул итүгә хокуклы:

- 1 һәм 2 төркем инвалидлар һәм (йә) аларның законлы вәкилләре (ата-ананың берсе, уллыкка алучы, опекун йә попечитель);

- Бөек Ватан сугышы ветераннары, Россия Федерациясе Геройлары, Советлар Союзы Геройлары, Дан орденының тулы кавалерлары, Социалистик Хезмәт Геройлары, Россия Федерациясе Геройлары, хәрби бәрелеше ветераннары;

- инвалид балалар, ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм балалар, шулай ук аларның законлы вәкилләре, бала хокукларын яклап мөрәҗәгать иткән вәкилләр;

- кабул итүгә 3 яшькә кадәр балалар белән килүчеләр, алар беренче чиратка хокук бирә торган документны күрсәтергә тиеш.

5. Беренче шәхси кабул итүгә хокукы булган гражданнар берничә икән, алар язылу тәртибе буенча кабул ителәләр.

6. Башлык һәм вәкаләтле вазифаи затлар гражданнарны читкә чыгып та кабул итәләр.

7. Шәхси кабул итү вакытында граждан шәхесне раслаучы документ күрсәтә.

5. Коррупцион юнәлештәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре буенча эш

1. Коррупцион юнәлештәге фактлар буенча мөрәҗәгатьләр ришвәтчелек һәм янап алу, вазифаи затның хезмәт урыныннан явызларча файдалану билгеләре булган эшләрне үз эченә ала.

2. Коррупцион юнәлештәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләрен караганда мөрәҗәгатьтәге белешмәләр, гражданның шәхси тормышына кагылышлы белешмәләр аның ризалыгыннан башка ачып салынмый. Язмача мөрәҗәгатьне вазифаи затка җибәрү фаш итү дип саналмый.

3. Коррупцион юнәлештәге фактлар буенча мөрәҗәгатьләр Советның гомуми бүлеге баш белгече тарафыннан исәпкә алына, теркәлә. Алар “ришвәтчелек” категориясенә кертелә.

4. Баш белгеч мондый мөрәҗәгатьләрне даими рәвештә анализлый һәм аларны вакытында ачыклап, сәбәпләрен бетерү өчен мондый мөрәҗәгатьләр гомумиләштерелә.

5. Кергән мөрәҗәгатьтә хокук эшенә каршы әзерләнә торган йә башкарыла, башкарылган эшләр һәм аларны башкаручылар турында белешмәләр булса, мондый мөрәҗәгать хокук саклау органнарына җибәрелә.

6. Бу мөрәҗәгатьләр белән эшләүче вазифаи затлар хезмәт информациясе һәм сер итеп сакланырга тиешле белешмәләр сакланышы өчен закон нигезендә шәхси җаваплы.

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башлыгы Карары белән расланган
20.08. 2018 № 67

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы
Советына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ үткәрү Тәртибе

1. Советның гомуми бүлеге баш белгече һәр ярты ел йомгаклары буенча гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне берләштерә.

2. Үткәрелгән анализ буенча бер елга ике тапкыр аналитик белешмә төзелә. Анда кергән, каралган язма мөрәҗәгатьләр, электрон документ формасындагы мөрәҗәгатьләр, шәхси кабул иткәндәге, күчмә кабул итү вакытындагы гражданнар саны, мөрәҗәгатьләрнең тематикасы, күрелгән чаралар, узган елның шул чоры белән чагыштырылып, анализ ясала.

3. Аналитик белешмә гомуми бүлекнең баш белегече тарафыннан районның рәсми сайтына урнаштырыла.

Кушымта №1
Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Советында гражданнар
мөрәҗәгатьләре белән эшләү
Тәртибенә

ГРАЖДАННАРНЫ КАБУЛ ИТҮНЕҢ ИСӘПКӘ АЛУ КАРТОЧКАСЫ

№ Кабул итү датасы “____” _____ 20____ ел

Район _____

Мөрәҗәгать төре: _____

Адрес, тел. _____

Гариза бирүченең исем-фамилиясе, атасының исеме _____
_____

Социаль хәле, ташлама _____

Кабатлану: Әйе, юк

Әңгәмәнең эчтәлеге:_____
_____
_____
_____
_____

Кабул итү нәтиҗәсе _____
_____
_____

Әңгәмәне алып барды: _____ _____
(Ф.И.О.) (имза)

“Телдән җавапка риза” _____
(мөрәҗәгать авторы)